Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кичүчат авыл Советы

КАРАРЫ

19 май 2022ел №44

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 84 номерлы «Кичүчат авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Кичүчат авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагынигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Кичүчат авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 84 номерлы «Кичүчат авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Кичүчат авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

6 пунктның в) пунктчасында «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга;

13 пунктта «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Кичүчат авылы, Юлдаш урамы, 2А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игъланитәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кичүчат
авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Шәйхетдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КИЧУЧАТОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ОГРН 1021601628355
Р.05-10979/16
КИЧУЧАТОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН 1644012286
КПП 164401001